ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $33^3$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$33^3$ статья. **Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага бирү**

1. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага бирү Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә, күрсәтелгән объектлар, инвестиция проектлары әлеге Кодекска кушымтада билгеләнгән критерийларга туры килгән очракта, торглар үткәрмичә башкарыла.

2. Социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеген арендага бирү турындагы юридик затның мөрәҗәгате Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә карала.

3. Социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объект, масштаблы инвестиция проекты әлеге Кодекска кушымтада билгеләнгән критерийларга туры килгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән органы юридик зат белән социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыруны яисә масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыруны күздә тота торган килешү (алга таба әлеге статьяда – килешү) төзи.

4. Юридик затка җир кишәрлеген арендага бирү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына килешү һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге, коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының әлеге Кодекска кушымтада билгеләнгән критерийларга туры килүе хакындагы дәлилле бәяләмә белән бергә кертелә.

5. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе юридик зат белән җир кишәрлекләре белән эш итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә җир законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

6. Әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатькә кушып бирелә торган документлар исемлеге, шулай ук килешүгә карата таләпләр, килешүне төзү һәм өзү, аңа үзгәрешләр кертү һәм аның шартларын үтәү мониторингын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Җир кодексына кушымта

**Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага торглар үткәрмичә бирү рөхсәт ителә торган мондый объектларның һәм проектларның туры килү критерийлары**

1. Социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объект стратегик планлаштыру документларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килгән һәм мәдәният, сәнгать, кинематография, спорт, төзекләндерү, сәламәтлек саклау, белем бирү һәм тәрбия эше, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү, коммуналь хуҗалык, халыкка

көнкүреш хезмәте күрсәтү объекты, шулай ук гидротехник корылма, күпкатлы һәм (яисә) җир асты машина кую урыны (парковка), күпкатлы гараж булган очракта, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген мондый объектны урнаштыру өчен арендага торглар үткәрмичә бирү рөхсәт ителә.

2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен арендага торглар үткәрмичә бирү мондый проект түбәндәге критерийларның берсенә туры килгән очракта рөхсәт ителә:

1) инвестиция проекты түбәндәге инвестицияләр күләмен күздә тота:

кимендә 350 миллион сум (индивидуаль торак йортларны һәм (яисә) күпфатирлы йортларны төзүдән тыш);

«Чаллы» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясе резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда шушы территориядә кимендә 20 миллион сум, шул исәптән юридик затны Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган үсеше алга киткән территорияләр резидентлары реестрына (алга таба – үсеше алга киткән территорияләр резидентлары реестры) керткәннән соң беренче ел дәвамында кимендә 2,5 миллион сум;

«Түбән Кама» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясе резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда шушы территориядә кимендә 15 миллион сум, шул исәптән юридик затны үсеше алга киткән территорияләр резидентлары реестрына керткәннән соң беренче ел дәвамында кимендә 2,5 миллион сум;

«Зеленодольск» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясе резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда шушы территориядә кимендә 10 миллион сум, шул исәптән юридик затны үсеше алга киткән территорияләр резидентлары реестрына керткәннән соң беренче ел дәвамында кимендә 2,5 миллион сум;

«Чистай» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясе яисә «Менделеевск» социаль-икътисадый үсеше алга киткән территориясе резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда юридик затны үсеше алга киткән территорияләр резидентлары реестрына керткәннән соң беренче ел дәвамында тиешле территориядә кимендә 2,5 миллион сум;

2) индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы идарәче компаниясенең инвестиция проекты гомуми күләме кимендә 350 миллион сум булган инвестицияләрне кертүне күздә тота. Гомуми инвестицияләр күләме идарәче компаниянең инвестиция проектында катнашучы индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы резидентлары тарафыннан кертелә торган инвестицияләрне исәпкә алып билгеләнә;

3) индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы идарәче компаниясенең инвестиция проекты тиешле индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы урнаштырыла торган авыл яисә шәһәр җирлеге территориясендә кимендә 50 эш урыны йә шәһәр округы территориясендә кимендә 100 эш урыны булдыруны күздә тота. Яңа эш урыннары саны идарәче компаниянең инвестиция проектында катнашучы индустриаль (сәнәгать) парк яисә сәнәгать мәйданчыгы резидентлары тарафыннан булдырыла торган эш урыннарын исәпкә алып билгеләнә;

4) инвестиция проекты капиталь төзелеш объектын төзү (индивидуаль торак йортларны һәм (яисә) күпфатирлы йортларны төзүдән тыш) белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кредит яисә башка финанс оешмалары эшчәнлегеннән зыян күргән затларга мондый кредит яисә башка финанс оешмаларының шушы затларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән оешманың тиешле реестрына кертелгән затлар алдында алар керткән акчалар күләмендәге бурычын каплау рәвешендә ярдәм күрсәтүне күздә тота. Әлеге пунктчада күрсәтелгән ярдәм чарасы күләме, кимендә 50 миллион сум булып, масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыруны күздә тоткан, рөхсәт ителгән файдалану төренә бирелә торган җир кишәрлегенең базар бәясеннән түбән була алмый;

5) инвестиция проекты, намуссыз төзүчеләрнең гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән, акчалары күпфатирлы йортларны төзү өчен җәлеп ителгән гражданнарга (алга таба – зыян күргән гражданнар) түбәндәге ярдәм чараларының берсен генә яисә берничәсен күрсәтеп, торак урыннарының гомуми мәйданы кимендә биш мең квадрат метр булган күпфатирлы йортны (күпфатирлы йортларны) һәм (яисә) башка капиталь төзелеш объектларын төзүне күздә тота (җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясының 2 пунктындагы $3^1$ пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш):

территориясендә масштаблы инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлектә урнашкан торак урыннарны зыян күргән гражданнар милкенә тапшыру. Тапшырыла торган торак урыннарның мәйданы территориясендә масштаблы инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлектә зыян күргән гражданнарга ярдәм чарасы күрсәтү өчен кирәк булган торак урыннар мәйданыннан арткан очракта, әлеге ярдәм чарасын зыян күргән гражданнарга карата башка муниципаль берәмлекләрдә күрсәтү рөхсәт ителә;

намуссыз төзүче тарафыннан төзелеп бетмәгән, төзелеше өчен зыян күргән гражданнарның акчалары җәлеп ителгән күпфатирлы йортның (күпфатирлы йортларның) төзелешен (төзелешен финанслауны) гамәлгә ашыру;

зыян күргән гражданнарга торак урыннарны, машина кую урыннарын һәм күпфатирлы йортта һәм (яисә) башка төзелеш объектындагы торак булмаган урыннарны тапшыру мөмкинлеген тәэмин итү максатында төзелештә катнашмаучы өченче затларның төзүченең аерылгысыз яхшырту элементлары урнашкан җир кишәрлегенә хокукларының залогы белән тәэмин ителгән йөкләмәләр буенча таләпләрен каплау. Әлеге ярдәм чарасы «Төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) вакытында өлешле төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча

гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла торган бөлгенлек (банкротлык) турындагы эш буенча башкаруны кузгаткан очракларда күрсәтелми;

Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән һәм «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруда катнашучы махсуслаштырылган оешма функцияләрен үтәүгә вәкаләт бирелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан төзелә торган күпфатирлы йорттагы (күпфатирлы йортлардагы) торак урыннарны алга таба зыян күргән гражданнар милкенә тапшыру максатларында әлеге күпфатирлы йортның (күпфатирлы йортларның) төзелешен финанслау.

Әлеге пунктчада күрсәтелгән ярдәм чарасы (чаралары) күләме, кимендә 50 миллион сум булып, масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыруны күздә тоткан, рөхсәт ителгән файдалану төренә бирелә торган җир кишәрлегенең базар бәясеннән түбән була алмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 05 март
№ 8-ТРЗ